

Тенгушево районында яшәvче хатын телефон мошенникларына 300 мен сум акча кvчергән.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын ММО 14 нче полиция пунктынын (Теньгушево районына хезмәт кvрсәтv буенча) «Темниковский» дежур бvлегенә 64 яшьлек жирле хатын-кыз морәжәгать иткән. Зыян кvрvче сvзләренчә, коннәр буе ана мессенджер аша билгесез номердан шалтырату кергән. Әнгәмәдәш vзен газ компаниясе хезмәткәре дип таныштырган һәм счетчикны алыштырырга тәкъдим иткән. Монын очен СМСтан кодны атарга кирәк булган. Атагач, әнгәмә тукталган.
Берникадәр вакыттан сон гариза бирvчегә янәсе банк хезмәткәре шалтыраткан һәм элегрәк анын белән мошенниклар элемтәгә кергәнен хәбәр иткән: алар хәзерге вакытта анын исеменнән финанс операцияләрен уздыруга ышаныч кәгазе рәсмиләштергәннәр. Санкцияләнмәгән гамәлләрне булдырмау очен барлык акчаларны да акчага әйләндерергә кирәк булган. Нәтижәдә зыян кvрvче банкка киткән. Анда, финанс оешмасы хезмәткәрләренен кисәтvләренә карамастан, зур суммада акча алырга тырышып караган. Әмма монын очен акчага алдан заказ бирергә кирәк булган. Шуна бәйле рәвештә ул 300 мен сум гына алган. Аннары аферист тәкъдиме буенча, акчаларны кvчерv унайлылыгы очен морәжәгать итvче мәгълvматларны чыбыксыз тапшыру технологияләренә ярдәм итә торган смартфон сатып алган һәм счет реквизитларын уку очен кушымта урнаштырган. Әмма шул рәвешле ул акчаны кvчерә алмаган һәм банкомат аша операция vткәрv очен янадан банкка киткән.
Акча кvчергәннән сон пенсионер мошенникларнын корбаны булуын анлаган һәм полициягә морәжәгать иткән. Хәзерге вакытта мошенниклык факты буенча жинаять эше кузгатылган.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы искәртә: уяу булыгыз. Сезгә карата законсыз операция ясалуы турында шикле шалтырату кергән очракта әнгәмәне озәргә кинәш ителә. Үз акчаларыгызны янәсе куркынычсыз счетка кvчермәгез, таныш булмаган затларга телефон аша vзегезнен шәхси мәгълvматларыгызны, шулай ук СМСтан кодны хәбәр итмәгез.